

Костромада Ботенроссия мәктәп театрлары житәкчеләре форумы узган, ә анда ботен илдән 300 педагог катнашкан. Шул исәптән, 89 тәрбия буенча директор кинәшчесе арасында Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбеннән Альфия Фатих кызы Муртазина да булган.
Быелгы чаранын топ темасы - авыл мәктәп театрларын vстерv булган. Мондый театрлар балалар очен ижади инициативаларны тормышка ашыру очен топ мәйданчыкларнын берсе булып тора.
Театрларнын житәкчеләре махсус тәжрибәгә һәм квалификациягә ия булырга тиеш, шуна кvрә форумда катнашучылар очен пьесаларнын автор текстларын, музыкаль һәм курчак тамашаларын актерлык импровизациясе элементлары, ритмика һәм инклюзив театрларнын эшенә багышланган мастер-класс-лар vткәрелгән.      Альфия Фатих кызы Муртазина кыска әнгәмәсендә болай ди:
- Авыл мәктәбе театрлары житәкчеләре Борис Щукин исемендәге театр институты спикерлары катнашында vткән мастер – классларда, дискуссияләрдә катнаштык. Шулай ук Мәскәv, Санкт-Петербург, Кострома режиссерлары, актерлары һәм Росдетцентр экспертлары белән очрашулар vтте. Мәсәлән, безнен мәктәптә татар телле “Афәрин-Браво” театрыбыз эшли. Сигезенче март бәйрәменә, башлангыч сыйныф укучылары белән, “Оч кыз”ны сәхнәләштердек- бу безнен тәжрибә. Ә форум кысаларында Кострома мәктәп драмтvгәрәкләрендә торле-торле момкинчелекләр тудырылган шартларда эш-ләvләрен, мәсәлән, сәхнә костюмнары, уты, декорация булган шартларда укучыларнын уйнавын кvрдек. Сокландыра. Бездә дә шундый шарлар тудырырга ярдәм итvчеләр табылса иде, укучыларыбыз сәләте тагы да нәтижәлерәк ачылыр иде.
Шундый тәжрибәне кvргәч, укучыларны шатландырып ниндидер яналыкны булдырырга телисен, эш очен стимул туа. Эчтәлекле, файдалы чара мина бик тә ошады. Мәсәлән, vземә укучылар кечкенә театры, шәvлә театры буенча кvп яналык туппладым. Зур рәхмәтемне, оештырып мине жибәргән очен, Росдетцентрга, региональ һәм муниципаль

кураторларыма белдерәм. Тагы бер тапкыр: бу кирәкле һәм кызыклы чара мина бик ошады.

**Наилә НАСЫРОВА**